| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2024 г.Казань № 375-20/тэ-2024

2025 елга Балтач муниципаль районы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының хуҗалык-эксплуатация хезмәте» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 12.12.2024 ел, № 31/1-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә кулланучыларга Балтач муниципаль районы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының хуҗалык-эксплуатация хезмәте» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – «Хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУ) тарафыннан җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2024 № 375-20/тэ-2024 карарына кушымта

2025 елга «Хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Балтач муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУ <*> | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 299,21 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 609,52 | - | - | - | - | - |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана, Россия Федерациясе Салым кодексының 145 статьясы нигезендә өстәлгән бәягә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүче вазыйфаларын башкарудан азат ителә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге